**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 29 апрель № 261

г. Казань

2015 елда «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын тормышка ашыру барышы һәм 2016 елга бурычлар турында

Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә дәүләт сәясәтен алга таба тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «2015 елда «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын тормышка ашыру барышы һәм 2016 елга бурычлар турында» хисабын хупларга.

2. Татарстан Республикасының энергетика комплексы предприятиеләренә («Генерирующая компания» ачык акционерлык җәмгыяте, «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте, җаваплылыгы чикләнгән «Түбән Кама ТЭЦ» җәмгыяте, «ТГК-16» ачык акционерлык җәмгыяте, «ТГК Уруссинская ГРЭС» ябык акционерлык җәмгыяте) Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2014 елның 30 маендагы ОД-168 нче боерыгы белән расланган 2019 елга кадәр перспектива белән 2014 елга Татарстан Республикасының электр энергетикасын перспективалы үстерү схемасы һәм программасы, инвестиция программалары, энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү программалары кысаларында энергетика инфраструктурасын техник һәм технологик модернизацияләү эшен көчәйтергә тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, хезмәттәшлек итү хакындагы килешүләрне гамәлгә ашыру кысаларында, ведомство буйсынуындагы оешмаларның «Данфосс», «Дженерал электрик», «Шнейдер электрик» компанияләре һәм башка халыкара компанияләр белән үзара хезмәттәшлеген оештыру эшен көчәйтергә.

4. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, мәнфәгатьле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары белән берлектә, 2016 елның 20 маена кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының энергия сервисы контракты механизмы аша Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрендә энергия саклау чараларын тормышка ашыру турындагы карар проектын (шул исәптән энергетика ресурслары өчен түләүгә чыгымнар составында энергия сервисы контрактлары өчен түләүгә Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан чыгымнарны планлаштыру һәм башкаруны оештыру буенча эш регламентына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каравына кертергә.

5. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән берлектә, кулланучыларны үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин итә торган пар казаннары биналарын модернизацияләгәндә һәм яңа энергетика куәтләре төзегәндә катнаш эшләп чыгару нигезендә кече энергетика объектларыннан файдалану мәсьәләсен карап тикшерергә.

6. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына 2016 елның 20 маена кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 10 июнь, б-914 нче боерыгына законнар таләпләре нигезендә энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасына кертергә мәгълүмат тапшыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарын билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәр әзерләргә.

7. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Энергия саклау технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесе белән берлектә:

2016 елның 1 июненә кадәр Татарстан Республикасының сәнәгатьне үстерү дәүләт программасы проектын сәнәгатьнең тиешле тармаклары буенча энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә максатчан индикаторларны билгеләү өлешендә тулыландырырга;

2016 елның 1 июленә кадәр Татарстан Республикасында энергия саклауны һәм җитештерүнең энергия нәтиҗәлелеген күтәрүне пропагандалау стандарты турындагы нигезләмә проектын эшләргә;

2016 елның 1 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 4 декабрь, 954 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасына, энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендәге чараларны һәм максатчан күрсәткечләрне, Татарстан Республикасының тармак дәүләт программалары кысаларында тормышка ашырыла торган әлеге чараларны

гамәлгә ашыру вакытларын һәм финанслау күләмнәрен яраштыру максатларында, үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәр әзерләргә;

2016 ел дәвамында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү буенча кабул ителгән муниципаль программаларның үтәлешен мониторинглауны оештырырга һәм 2016 елның 30 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына гомумиләштерелгән мәгълүматны кертергә.

8. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына 2016 ел дәвамында Татарстан Республикасы оешмаларында һәм учреждениеләрендә тормышка ашырыла торган энергия саклау өлкәсендәге чараларны һәм проектларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту юлы белән энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрүне пропагандалау эшен үткәрергә.

9. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына 2016 елның 1 июленә кадәр энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә кабул ителгән муниципаль программаларны аларның гамәлдә булу вакытын 2020 елга кадәр озайтуны исәпкә алып актуальләштерергә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең бердәм рәсми порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

10. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры А.Ә.Кәримовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\261.docx